Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Советы КАРАРЫ

2022 елның 11 феврале 91№

Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Советының 2018 елның 12 апрелендәге «Әлки муниципаль районы» муниципаль берәмлеге депутатлары, даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затлары, контроль-хисап органнары рәисләренең хезмәте өчен түләү тәртибе һәм шартлары турындагы нигезләмәне раслау хакында» 147 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

2021 елның 1 июлендәге «Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнарын оештыруның һәм аларның эшчәнлегенең гомуми принциплары турында» Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 77-ТРЗ номерлы Федераль закон, 2011 елның 07 февралендәге 6-ФЗ номерлы Федераль законның 5 статьясының 3 өлеше нигезендә контроль-хисап органының аудиторы хезмәтенә түләү тәртибенә үзгәрешләр өлешендә, 2021 елның 4 октябрендәге «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 77-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 елның 17 ноябрендәге 1087 номерлы карары нигезендә Әлки муниципаль районы Советы Карар итте:

1. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Советының 2018 елның 12 апрелендәге «Әлки муниципаль районы» муниципаль берәмлеге депутатлары, даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затлары, контроль-хисап органнары рәисләренең хезмәте өчен түләү тәртибе һәм шартлары турындагы нигезләмәне раслау хакында» 147 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- Нигезләмәнең 1 нче кушымтасы 2.5 бүлеге 2.5 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Әлки муниципаль районының контроль-хисап органы аудиторына айлык акчалата түләүдән һәм еллык түләүле ял биргәндә бер мәртәбә түләнә торган түләүдән тыш, өстәмә рәвештә ай саен акчалата бүләкләү, эш нәтиҗәләре буенча премия, шулай ук муниципаль хокукый актлар нигезендә башка түләү түләнергә мөмкин. Шул ук вакытта аудиторга айлык акчалата түләүләрнең гомуми күләме Әлки муниципаль районының контроль-хисап органы рәисенә акчалата түләүләрнең 0,6 айлык җыелма күләменнән арта алмый».

2. Әлеге карар Әлки муниципаль районының http://alkeevskiy.tatarstan.ru рәсми сайтында басылып чыккан көненнән үз көченә керә.http://alkeevskiy.tatarstan.ru

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны «Татарстан

Республикасы Әлки муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы» МКУсенә йөкләргә.

Совет Рәисе,
Әлки муниципаль район Башлыгы: А.Ф. Никошин